**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы**
**КАРАРЫ**

**2 ноябрь 2018** **№ 160**

**Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш), индивидуаль эшкуарларга, физик затларга - Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районында товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләренә субсидияләр бирү Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. 2011 елның 18 июлендәге 70 номерлы Карары (2018 елның 31 июлендәге 94 номерлы Карар редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш), индивидуаль эшкуарларга, физик затларга - Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районында товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирү Тәртибенә үзгәрешләр кертергә:

1) Тәртипнең 4 пунктын киләсе редакциядә бәян итәргә:

“4. Субсидияләр кече һәм урта эшкуарлык субъектларына муниципаль районның социаль-икътисадый үсешенең өстенлекле максатчан юнәлешләренә, шул исәптән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына бирелә:

а) Кама Тамагы муниципаль районы территориясендә авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү һәм эшкәртү;

б) районның халык аз яши торган пунктларына беренче чиратта товарлар китерү;

в) халыкка мунча хезмәтләре.”.

2. Әлеге Карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматенең рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы

муниципаль районының “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Кама Тамагы муниципаль районы**
**Башлыгы, Кама Тамагы муниципаль**
**районы Советы рәисе** **П.Н. Лоханов**